ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» апреля 2026 ел № 107

«Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән акчалата түләүләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы 151 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар акчалары исәбеннән акчалата түләүләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 12 маендагы 151 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктын төшереп калдырырга.

1.2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының 2026 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенең 1 пунктын (алга таба - Тәртип) түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы спорт министрлыгы башкара торган спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмаларында, спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы

муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне билгеләргә: ай саен стимуллаштыручы өстәмә 2 510 сум күләмендә эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә, әмма аена 2 510 сумнан да артык булмаган күләмдә кертергә;
хуҗалыкны төзекләндерүгә 100 000 сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү.»

1.3. Тәртипнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә « " яшь белгеч - 35 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданы («Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 30.12.2020 ел, 489-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 3 өлешендә каралган очраклардан тыш), төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) һөнәри белем бирү программалары буенча укуын тәмамлаган, алган квалификациясе нигезендә беренче тапкыр эшкә урнаша торган, шул исәптән хезмәт стажы булган, шул исәптән төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яисә) һөнәри белем бирү программалары буенча укыту.» .

2. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Н. Бадахшинга йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**